ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«** 02 **»** 11 **2024ел** **№**986

«2024-2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерүнең һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында»гы 2012 елның 14 июлендәге 717 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында»гы 08.04.2013 елның 235 санлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында авыл хуҗалыгы продукциясенең конкурентлыкка сәләтен арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 22.10.2024 елның № 952 санлы карары белән расланган «2024-2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның 1 пунктында 7 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләме - 199,753 млн. сум, шул исәптән:<br>2024 ел - 78,437 млн. сум;<br>2025 ел - 121,316 млн.сум.<br>Программаны финанслау чыганаклары:<br>- Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты - 143,371 млн. сум.; |

| | |
|---|---|
| | - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле бюджеты - 3,860 млн. сум.,<br>- бюджеттан тыш акчалар - 52,522 млн. сум. |

1.2. Программаның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**6. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары**

Программаны күп каналлы принцип буенча финанслау планлаштырыла: федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Ютазы муниципаль районы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына.

| Чыгымнар чыганаклары | Финанслау күләме млн. сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| ТР берләштерелгән бюджеты | 187,433 | 44,062 | 27,910 | 115,461 |
| Ютазы муниципаль районы бюджеты (алга таба - МБ) | 5,667 | 1,807 | 1,855 | 2,005 |
| Башка чыганаклар | 56,194 | 3,672 | 48,672 | 3,850 |

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 22.10.2024 елның № 952 санлы карары белән расланган «2024-2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасы кушымтасына (алга таба - кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Кушымтаның 3.1 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1 | Нәселле терлекчелеккә ярдәм | ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы<br>Ютазы МР Башкарма комитеты | ТР берләштерелгән бюджеты | 0 | 6,2 | 0 | 6,2 |

3. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет төзегәндә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Программаны башкаручыларга программаны вакытында һәм тулысынча үтәүне тәэмин итәргә киңәш итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы З.З. Гыйбадуллина